| | | |
|---|---|---|
| “Килешенде”<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары-мәгариф идарәсе җитәкчесе<br>_______________<br>И.И.Ахмадуллин | “Килешенде”<br>Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе<br>_______________<br>Р.Р. Зайдуллин | “Раслыйм”<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Г.Х.Хабибрахманов исемендәге Олыяз авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе<br>_______________<br>Л. Х. Аухадиев |

**Россия Федерациясендә Халыклар бердәмлеге, Татарстан Республикасында Хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы, М. Җәлилнең тууына 120, Г. Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан укучылар һәм педагогик хезмәткәрләр өчен уздырылучы V республикакүләм “Туган тел – тормыш көзгесе” конференция нигезләмәсе**

**Гомуми белешмә**

Укучылар, педагогик хезмәткәрләр өчен уздырылучы V республикакүләм “Туган тел - тормыш көзгесе” конференциясе Татарстан Республикасы Язучылар берлеге ярдәмендә Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе һәм «Г.Х.Хабибрахманов исемендәге Олыяз авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе инициативасы белән үткәрелә.

Конференция нигезләмәсе һәм кирәкле мәгълүмат Олыяз урта мәктәбенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Оештыру комитеты (1нче кушымта) түбәндәге бурычларны хәл итә:

- конференциягә нигезләмә, әзерлек һәм үткәрү планы эшли;
-жюри составын һәм конференция беркетмәләрен раслый.

Оештыру комитеты конференцияне үткәрү шартларын һәм вакытын үзгәртү хокукларын үзендә калдыра.

**Конференциянең максаты**

Укучыларның иҗади һәм интеллектуаль потенциалын үстерү, федераль дәүләт стандартларын гамәлгә ашыру шартларында шәхесне күрсәтү һәм үстерү өчен перспективалы алымнар эзләү, рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәле системасын булдыру.

**Бурычлар**

-конференциядә катнашучыларны рухи кыйммәтләргә, милли-мәдәни традицияләргә, телгә тарту;
- нәфис сүз осталарын барлау; аудитория каршында чыгыш ясау күнекмәләрен үстерү;
- жирле материалларга нигезләнеп туган як тарихын өйрәнүне булдыру;
-нәсел шәҗәрәсе тикшеренүләре традицияләрен саклау һәм үстерү;
-гаилә традицияләрен һәм буыннар арасындагы элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү;
- үсеп килүче буында социаль-актив тормыш позициясе формалаштыру;
- педагогик тәҗрибәне һәм һөнәри осталыкны тарату өчен шартлар тудыру;
- милли үзаң һәм патриотик хисләр тәрбияләү.

**Конференциядә катнашучылар**

Конференциядә катнашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәктәпкәчә белем бирү, урта һәм гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-11 сыйныф укучылары, укытучылар, тәрбиячеләр чакырыла.

**Конференцияне үткәрү вакыты**

Конференция 2 турда үтә:

беренче тур – эшләрне кабул итү (*2026 нчы елның 5 нче апреленә кадәр*), тикшереп, иң уңышлыларын сайлап алу. Икенче турга үтүчеләр исемлеге Олыяз урта мәктәбенең рәсми сайтында урнаштырыла.

икенче тур – 2026 нчы елның 10 нчы апрелендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Г.Х.Хабибрахманов исемендәге Олыяз авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә.

**Конференция юнәлешләре**

1. **1. “Нәни сандугач”** (мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалар арасында Туган тел темасына җыр, нәфис сүз бәйгесе).

**Бәяләү критерийлары:**

- катнашучының яшь үзенчәлекләренә туры килүе;
-кызыклы идеяләр һәм якты образлар бирелеше;
- пауза, логик басым куелышы;
- артистлык сәләте;
-тыңлаучыларга текстның мәгънәсен җиткерә алу.
-теманың ачылу дәрәҗәсе;
- сәнгать осталыгы (җырны башкару сыйфаты).

**2**. **“Сөйлим әле туган телемдә”** (1-4нче сыйныф укучылары арасында Г. Тукай һәм М. Җәлил шигырьләрен сәнгатьле сөйләү бәйгесе).

**Бәяләү критерийлары:**

- катнашучының яшь үзенчәлекләренә туры килүе;
-кызыклы идеяләр һәм якты образлар бирелеше;
-әдәби тел, тасвирлауның образлылыгы;
-урынлы ритм һәм сөйләм темпы;
- пауза, логик басым куелышы.
- артистлык сәләте;
-тыңлаучыларга текстның мәгънәсен җиткерә алу.

**3. “Мирас”** ( 5-11 сыйныф укучыларының музей һәм җирле материалларга нигезләнеп, авыллар тарихын, нәсел шәҗәрәләрен, күренекле шәхесләр тормышын чагылдырган фәнни-эзләнү эшләре).

**Бәяләү критерийлары:**

- эшнең фәннилеге;
- заман таләпләренә туры килүе;
- эшнең максатын дөрес билгеләү;
- логик яктан дөрес фикерләү;
- дәлилләнгән нәтиҗәләр ясый белү;
- эш нәтиҗәләренең фәнни һәм гамәли әһәмияте
- кулланыла торган тарихи чыганакларнын төрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре h.б.);
- шәҗәрә агачы сурәте (схемалар) һәм аның тасвирламалары булу.

**4. Укытучы остаханәсе** (укытучылар һәм тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәсен чагылдырган докладлар, мастер-классլар)

**Бәяләү критерийлары:**

- теманың актуальлеге һәм әһәмияте;
- эчтәлеге һәм формасының тирәнлеге;
- фәнни-методик кыйммәте;
- практик әһәмияте һәм кулланылышы;
- аудитория белән профессиональ аралаша алу.

**Конференцияне үткәрү шартлары һәм тәртибе**

Конференция татар телендә генә уздырыла.
Конференциядә катнашу өчен 2026 нчы елның 5 нче апреленә кадәр гариза (2 нче кушымта) һәм эшләрне җибәрергә кирәк.

❖ **“Нәни сандугач”** юнәлешенә гаризалар һәм видеоязмалар (mp4, avi форматларында) elmiranurieva@list.ru почтасына кабул ителә. Юнәлеш өчен җаваплы: Нуриева Э.С., мәктәпкәчә белем бирү баскычы методисты, тел: 89270303941

❖ **“Сөйлим әле туган телемдә”** юнәлешенә гаризалар һәм видеоязмалар (mp4, avi форматларында) Liliahab1978@mail.ru почтасына кабул ителә. Юнәлеш өчен җаваплы: Хабибуллина Л.Я. башлангыч сыйныфлар укытучысы, тел: 89370047237

❖ **“Мирас”** юнәлешенә фәнни-тикшеренү эшләре rezidagubaydullina.66@mail.ru почтасына кабул ителә. Фәнни-тикшеренү эшләре мөстәкыйль рәвештә башкарылган булырга тиеш. Реферат тибындагы эшләр кабул ителми. Эшләр 1,5 интервал аша Times New Roman шрифты,14 белән языла; кырлар: уңнан – 15мм, сулдан – 30мм, өстән һәм астан – 20мм (3 нче кушымта). Юнәлеш өчен җаваплы: Губайдуллина Р. М., башлангыч сыйныфлар укытучысы, тел: 89393934389

❖ **“Укытучы остаханәсе”** юнәлешенә гаризалар һәм эшләр shulpan16@mail.ru почтасына кабул ителә. Юнәлеш өчен җаваплы: Шакирова Ч. Т., башлангыч сыйныфлар укытучысы, тел.89393601016

**Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау**

Жюри катнашучылар арасыннан җиңүчеләрне билгели.

Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аның рәисе тарафыннан раслана.

Конференция нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең дипломнары, катнашучылар сертификатлар белән бүләкләнәчәк.

**Бәйгене финанслау**

Бәйге катнашучыларның кертемнәре хисабына финанслана. Һәр катнашучының кертеме 200 сум күләмендә билгеләнде. Түләү бәйге көнне теркәлү вакытында оештырыла.

Кушымта №1

## Оштыру комитеты составы

| № | ФИО | Эш урыны, вазифасы | |
|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадуллин И.И. | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары-мәгариф идарәсе җитәкчесе | Оештыру комитеты рәисе |
| 2 | Бакланова М. Г. | Мәгариф идарәсе, укыту-методик эшләр буенча мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары | Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| 3 | Шаймарданова А. М. | Мәгариф идарәсе методисты | Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| 4 | Аухадиев Л. Х. | Олыяз авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры | Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| 5 | Хурамшина А. Н. | Олыяз урта мәктәбе, укыту эшләре буенча директор урынбасары | Оештыру комитеты әгъзалары |
| 6 | Хабриева Л. В. | Олыяз урта мәктәбе, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары | |
| 7 | Гилметдинова З. Ш. | Олыяз урта мәктәбе, педагог – оештыручы | |
| 8 | Гафиева А. Р. | Олыяз урта мәктәбе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы | |
| 10 | Хабибуллина Л. Я. | Олыяз урта мәктәбе, башлангыч сыйныфлар укытучысы | |
| 11 | Шакирова Ч. Т. | Олыяз урта мәктәбе, башлангыч сыйныфлар укытучысы | |
| 12 | Губайдуллина Р. М. | Олыяз урта мәктәбе, башлангыч сыйныфлар укытучысы | |
| 15 | Нуриева Э. С. | Олыяз урта мәктәбе, мәктәпкәчә белем бирү баскычы методисты | |

Кушымта №2

“Туган тел- тормыш көзгесе” конференциясендә катнашу өчен гариза

| | |
|---|---|
| Катнашучының исем – фамилиясе, сыйныфы | |
| Юнәлеше | |
| Укытучының исем – фамилиясе | |
| Район, мәктәп исеме | |
| Әсәрнең исеме (фәнни эш, доклад, мастер класс темасы) | |
| Педагогның элемтә өчен телефоны | |
| E-mail | |

Кушымта 3

Россия Федерациясендә Халыклар бердәмлеге
Татарстан Республикасында Хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы
М. Җәлилнең тууына 120, Г. Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан
укучылар һәм педагогик хезмәткәрләр өчен уздырылучы
V республикакүләм "Туган тел-тормыш көзгесе" конференциясе

**Фәнни-эзләнү эшенең темасы:**

**"................"**

**Юнәлеш :**

**"........."**

Эшне башкаручы: ФИО,
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
"Г.Х. Хабибрахманов исемендәге Олыяз авылы урта гомуми
белем бирү мәктәбе" ... нче сыйныф укучысы

Фәнни җитәкче: ФИО,
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
"Г.Х. Хабибрахманов исемендәге Олыяз авылы урта гомуми
белем бирү мәктәбе" ..........

2026